
# Кайбыч, Норлат сөйләше




Башкарды:
Садриева Э.Р.

Норлат,Кайбыч сөйләше Татарстанның Тау ягында Норлат, Кайбыч, өлешчә Апас һәм Яшел Үзән, Чувашиянең Урмар районнарында таралган. Төньякта дөбъяз, көньякта кама тамагы сөйләшләре белән чикләнә.






# Фонетик үзенчәлекләр

**Сузыклар. ы~а**(фигыль формаларында , кайбер сүзләрдә):*йазырга*-йазарга, *йатыр*-йатар, *тотыр*-тотар, *сатырбыз*-сатарбыз; *баргынчы*-барганчы, *чыккынчы*-чыкканчы; *йырлыш*-диал.йырлаш-җырлаш, *урлыш*-урлаш;*тустагын*-тустаган, *ыңганчы*- диал.аңынчы-аңа кадәр.

**ы~а** *шушанда*-шушында, *шушандый*-шушындый.

**э(е)~ә** тәңгәллеге – р кушымчалы фигыльләрдә һәм –ганчы\- гәнче кушымчалы хәл фигыльләрдә күзәтелә:*кисер*-кисәр, *китер*-китәр, *сөзер*-сөзәр, *килгенче*-килгәнче, *җиткенче*-җиткәнче;

**ә~э(е):** *нәчкә*-нечкә, *әрләү*-эрләү, *әвәслек*-әвеслек һ.б.

**ә~и** билгеле бер төркем сүзләрдә күзәтелә:*әпи*-ипи, *кәтек*-китек, *мән*-мин, *тәкле*-тикле;



# Тартыклар.

**п~ф** тәңгәллеге ике төрле күренешне чагылдыра.

а)*керпек*-керфек, *җапырак*-йафрак(яфрак), *тупырак*-туфрак.

ә) алынмаларда төрки телләр өчен чит булган ф авазын алмаштыру:*Патыйма*-Фатыйма, *Сапа*-Сафа, *Капиз*-Хафиз, *пирме*-ферма.

**н~ң.** Әдәби телдәге ң авазына тел очы н тартыгы тәңгәл килү иялек килеше кушымчаларында һәм 2 нче зат берлек сан хикәя фигыльләрдә күзәтелә:*аwылнын*-аwылның, *безнен*-безнең, *китәсен*-китәсең, *сугасын*-сугасың, *сун*-соң.

**с~ч** гач\гәч кушымчасында: *кургәс*-күргәч, *белгәсен*-белгәч. Рус алыналарында даими рәвештә **ч~с:** *чипарат*-сепарат, *чимийә*-семья, *эчтина*-стена, *чустыра*-сестра, *чичла*-число, *чилом*-силой.

**т~ч.** Түбәндәге сүзләрдә сүз башында **т~ч** күренеше сөйләшнең төньягында күзәтелә: *тиш*-чиш, *тишен*-чишен.



# Морфологик үзенчәлекләр

**Исемнәр.** – кач \кәч иркәләү-кечерәйтү кушымчасын куллану очрагы теркәлгән:*Бәбекәчем , мәңа да күрсәт әле шал күлмәгеңне*.

Төшем килеше кушымчасының бөтенләй әйтелмәү очраклары теркәлгән:*Кулым(кулымны) пешердем, бәйләгәс тә аwырта.*

Тел очы н авазына беткән исемнәрнең төшем һәм чыгыш килешләрендә икеләтелгән –нн- кыскару очрагы теркәлгән. *Урманы(урманны) кисеп бетерә нийәстә була?*





**Алмашлыклар.** Зат алмашлыклары:*мән*\мин, *сән*\син, *ул*\ал. Мәсәлән:*Мән* (мин) *тотоп карамадым, кулым чи*(юеш). *Тамыр табанны чаналар барыйы мин белердә дә. Сән*(син) *бәби чәйенә аппарасың коймак путнус белән.*

Кайбыч сөйләшендә мин алмашлыгының иялек килешендә н төшү очраклары бар: *минем*\мийем. *Мийем* (минем) *әнинең күлмәге киң куштанны* (балайтәкле) *булган.*

Иялек килешендә ң авазына тел очы н туры килергә мөмкин:*безнен*-безнең, *синен*-синең.

1 нче һәм 2 нче зат берлек сандагы алмашлыклар юнәлеш килештә *мәңа*(миңа, *сәңа*(сиңа) формаларында да кулланыла.

Бу алмашлыкларның чыгыш килеше дә үзенчәлекле: миннән\минән\мийән, синнән\синән\сийән. Мәсәлән: *Мийән*(миннән) *алда эшләүче шупир җийган машина ул. Аны мин үзем сийән сорамакчы +-йым. Сийән* (синнән)*безрик табанак*(бераз тәбәнәк)..

Күрсәтү алмашлыклары:*шул*\шал-шул*, шушал*-шушы, шушандый, шандый-шундый, *тее*\теге\тийе\тиге-теге, бу, бысы*босо*-монысы, *ансы*\алсысы-анысы, *ул*\ал-ул, *ана*-әнә, *мона*-менә. һ.б.

Алмашлыкларның юнәлеш килешендә н янында г тартыгы һәм борынгы –ар\әр кушымчасы саклану үзенчәлекле :*Аңгар*-аңа*, моңгар*-моңа, *анысыңгар*-анысына*, тегеңгәр*-тегеңә.



**Саннар.** Җыю саны өстәмә –лап\ләп кушымчасы ала: *Мийем каз бәпкәсе бар бишәүләп(бишәү), мәйхәнә киләм. Алтаулап(алтау) киләләр энде туйга, кызның атасы-анасы. Әллә умберәүләр (унберәү) диде, әллә уникәүләп, хәтерләмим. Сигезәүләп җаттык бер палатада. Балаларыгыз ничәүләп?*



Җыю саннарын аергыч ролендә куллану очраклары күзәтелә: *Акҗегеттә(ав.ис.) берәү тәтәйебез (бер апабыз) бар.*



**Рәвешләр.** Вакыт рәвешләре ел фасылларын белдерә торган сүзләрдән түбәндәге кушымчалар һәм аналитик төзелмәләр ярдәмендә ясала.

а)- кы\-ке\-гы\ге+көннө:*Кышкы көннө(кышын, кыш көне) шулый әкрен генә йотабыз.*

ә) *урын-вакыт килешендә:Көз көннөндә сукалый да арыш чәчә.*

б) бернинди грамматик күрсәткечсез, ягъни лексик-семантик ысул белән:*Җәш тай була бийылгы җәаз(язын, яз көне) туган*.

в) әдәби форма:*Җәен дә, кышын да урманда эшләгән мин.*

г) *–лата\-ләтә:Көзләтә булса туй, кабак бәлешләре дә пешерәбез.*

Дәвамлы вакыт рәвешләре, нигездә, әдәби телдәгечә ясала*: Бийыл кыш буйы а wырды. Төнө буйы утырдым.*

Шул ук вакытта, бу мәгънәдә  башка конструкцияләр дә күзәтелә:*Бөтөн көн (көн буена) утырыйк шалый (шулай). Бөтөн көн озон(көне буе) шулар артыннан җөри бит.*

Әwәле, элгәре, элке кебек вакыт рәвешләренең кулланылышы әдәби телдәгечә. Кайбер мисаллар: *Әwәле монда эшләдийе, ыстансада. Мөң тәңкә акча күп булган элке. Элгәре Кәwәлдә (ав.ис.) карусил булганмы?*





**Фигыльләр.** Затланышлы формалар. Хикәя фигыль. Кайбыч сөйләшендә категорик үткән заман *(–ды\-де),* әдәби телдән аермалы буларак , -ган\-гән кушымчалы сыйфат фигыль белән белдерелә, хәбәрлек кушымчалары ялганмый. Мәсәлән, *Без кичә печәнгә барган(бардык.). Сез Казаннан кайчан кайткан(кайттыгыз)? Мин кызыл казармаларны күрсәткән (күрсәттем) аңа.*

Күптән үткән заман (-ган\-гән иде\-ыйы\ийе), Тау ягының башка сөйләшләрендәге кебек, -ды\-де иде\-ыйы\-ийе формасы белән белдерелә:*Мин синең җанга килдемийе (килгән идем). Без Себердә тордогыйы(торган идек). Мин Чиләбегә укырга җибәрделәрийе (җибәргәннәр иде).*

*-а\-ә торган+ыйы: Ужҗым әйбәт була торганыйы, ат алып сугым симертә торганыйык.*

*ыр\ер+-ыйы\-ийе:Эй, йәш тайларҗигеп кайтырларыйы. Җаңа килен бөтен эчтинага (стенага)сөлгө элеп тутырыйы.*

*-адыр\-әдер+-ыйы\-ийе:Метечләр буладыр ийе, атыб-атыб уйныйдырыйык(кузна уены турында). Аршин башлы, аршин чирекле сөлгеләр чүплидерийек.*

Күзәтүләргә караганда, норлат, кайбыч сөйләшендә *–адыр\-әдер иде* формасының кулланылышы чикләнә төшә. Өченче зат күплектә бу мәгънәдә –а\-ә иде(+-ыйы\ийе) кушымчалы хикәя фигыль кулланыла:*Коро йәшен (аҗаган)суккан диб әйтәләрийе, чикләwекләр кара корок (сукыр) булса. Әтиләр базардан калач апкайталарыйы.*



**Ярдәмлек сүз төркемнәре.**

**Бәйлекләр.** Кебек бәйлегенең тагын күwek \күк вариантлары бар:*Шаның күwek*(шуның кебек) *агачларны кискән без.*

Тикле бәйлеге тәкле вариантында да күзәтелә:*Урманга тәкле* (тикле) *җәйәү барам, арымыйм.*

**Теркәгечләр.** Норлат сөйләшендә *әгәреңки*(әгәр) варианты кулланылуын күрсәтеп үтәргә кирәк:*Әгәреңки Фази бабый булса, ул сүләрийе сәңа аwыл тарихларын.*



**Кисәкчәләр.** Фигыльләрдә –мы\-ме сорау кисәкчәсен зат кушымчасыннан алда куллану:*Чынайак табагы апкил, чәй эчәмесең*(эчәсеңме)*? Монда гына йатып торамсыз*(торасызмы)?

# Синтаксик үзенчәлекләр.

Компонентлары бер-берсенә нисбәтлек төшенчәсе белән бәйле булган исем-исем сүзтезмәләрендә тартым кушымчаларын кулланмау очраклары күзәтелә:*Әпи кабартманы* (диал. Ипи кабартмасын-көлчә) *кесәгә тыктым. Шанда җырак түгел, ыстансы җанда*(янында) гына. *Сугыш җылны* (елында) *акуп казыдык. Кай җакта ул Саба, Казан җүндә*(янында, ягында) *түгелме?*

Икеләнүне, шөбһәләнүне бул ярдәмче фигыле белән белдерү:*Үзегез беләсез булыр күпме икәнен.*

Сорауны, икеләнүне, , шөбһәләнүне, фараз итүне белдерә торган җөмләләрдә сорау кисәкчәсе хәбәр составында, зат кушымчалары билгесезлек белдерә торган – дыр\-дер кисәкчәсеннән алда була:*Болар алганмыдыр*(алгандырмы)?

Сорау җөмләләрне әллә кисәкчәсе һәм интонация белән оештыру:*Әллә сәңа килмәде?*





# Лексик үзенчәлекләр

Норлат, Кайбыч сөйләшендә шактый бай диалекталь лексика табыла, алар тормыш-көнкүрешнең төрле тармакларына карый.

*Туганлык-кардәшлекне белдерә торган диалекталь сүзләр: җанагый*-хатынга иренен энесе, *печкәчи*-хатынга иренең сеңлесе, *малый*-бала, *ир малый*-малай, *кыз малый*-кыз (бала), *тәтәй*-апа, әтинең апасы, *тәти абзый*-әнинең энесе.

*Бәйрәмнәр белән бәйле сүзләрдән сабанту* (сабантуй) борынгы формасы сакланган, *Кала алы, Тикен, Качирмә, Җуwа*- җыен исемнәрен күрсәтергә кирәк.

*Кешене төрле яклап сыйфатлый торган сүзләр: суwык чырай*-караңгы чырай, *тибеи* тиз, *как-сук иту*-кагу, кимсету, *кожғоту*-котырту, *күчмәү*-шауламау, *бору*-сыгу, *дырын*-көтмәгәндә, *әсбе*-сызлавык, *туңдыру* бизгәк, *ләпес*-тимерәүгә сөртә торган дару, *җепелдәwек*-күп сөйли торган, *буйдак*-тайлак-эшлексез, эш яратмаган кеше, ялкау, *гүсбәт*-зур гәүдәле ялкау кеше






*Кием-салым:* *пәрдә*-яшь киленнең килен булып төшкәндә битенә каплаган бөркәнчеге, *хәстә*-бөти, амулет(бала бишегенә куела), *калуш*-киез ката, *кәллә*-түбәтәй, *уңгер*-изүчә(хатын-кыз бизәнү әйбере), *әрешкә*-кешлеккә.

*Аш-су:* *әпи кабартмасы*-көлчә(ипи камырыннан мич каршында пешереп алынган камыр ашы), *җакмыш*-кыстыбый, *тәти катламасы*-юка камырга төйгән киндер орлыгы ягып, почмакларын каплап куеп пешерелгән камыр ашы һ.б.

*Терек һәм терек булмаган табигать:* *коро йәшен*-аҗаган, *нугый* чуерташ һ.б.

*Хайваннар дөньясы:* *кийек*-тычкан, *җүwешмән*-кыргаяк, *куwакал\кукал*-үрдәк, *гуңгыйк*-тирес корты, *копшаңгы*-каты таракан, *әрешмән*-үрмәкүч, *шөки*-агач корты, *ушна*-кыр тычканы.






# Сөйләү үрнәкләре

Кирпеч сугасы булса\әwәл балчыгын чыгармалы\\су сипмәле\\анары томалап куймалы пешсен дип\\бер атна торгандыр пешеп\\анары үзләндереп айак белән таптаган\\кумка йасаган\анары суккан\\айырым-айырым утыртып куйган\җаткыргач җарыла бит ул\\шулый иттереп мәйхәнә килеп җаткан\\аны көз көнө эш беткәс җандырган\ учак җасап җар кырыйында\\бер пичкә мең өч җөз кирәк\дәүрәгенә күбрәк кирәктер энде\\

Сөйләүче:Сибгатуллин Нәби, 86 яшь

Татарстан, Яшел Үзән районы, Акъегет авылы








Photographer Sergey Makarov



# Сөйләү үрнәге.

# Кулланылган әдәбият

Г.Х. Ахатов “Татарская диалектология”;

Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова “Татар халык сөйләшләре” (беренче китап);

Ф.Юсупов “Морфология татарского языка